
22 декабрь - татар әдәбияты классигы Шәриф Камалнын бакый доньяга кvчкән коне. Һәр ел, традиция буенча, Рузаевка районы Татар Пешлә урта мәктәбе укучылары якташларынын истәлек тактасына чәчәкләр салалар.

Бvген дә балалар, мәктәп директоры Флора Әхмәтжан кызы Шамонова белән укытучылар житәкчелегендә, истәлек тактасы янына жыелдылар һәм Шәриф Камалетдин улы турында сойләштеләр.
Бу конгә, әлбәттә, әзерләнv булды. Тугызынчы сыйныф укучылары Шәриф Камалга куелган таш янын (туган йорты урынында) кардан чистарттылар. Ә инде 22нче декабрь конне vзебезнен авылдашыбызга, классик язучы, драматург, тәржемәче Шәриф Камалны искә алып, чәчәкләр куйгач, истәлекле таш янында ук укучылар белән Шариф Камал турында әнгәмә vткәрдек. Истәлекне мән-геләштереп, фотога да тешердек.

Шул ук конне Шәриф Камал исемен горур йорткән Татар Пештәсе урта мәктәбебездә якташыбызга багышлап, барлык классларда торле кичәләр, дәресләр һәм класс сәгатьләре vткәрелде.
Алдан искәртәм: 2024 нче елнын 27 нче (иске стиль буенча - 15) февралендә Шәриф Камалнын (Шәриф Камалетдин улы Байгильдеев) тууына 140 ел тула. Бу конне лаеклы билгеләп vтv максаты белән мәктәбебез инде әзерлек алып бара.

**Сания САЛЯЕВА**